**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» март 2021 ел № 19

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2020 елның 12 маендагы № 13-20р күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның күпләп ял итүе һәм суда коткару чаралары өчен җиһазландырылган урыннар булмау сәбәпле, су объектларының һәм елгаларының санитария-гигиена нормаларына туры килмәве, елгаларда һәм сулыкларда бәхетсезлек очракларының иминлеген тәэмин итү, кисәтү һәм санын киметү максатыннан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыярга.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә су объектларында су коенуны тыю турындагы әлеге карар белән танышуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Республикасы Азнакай муниципаль районы "Актүбә шәһәр тибындагы

поселок" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына су объектлары янында су коенуны тыю турындагы мәгълүмат белән кисәтү аншлаглары урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов